ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

2020 елның 1 апреленнән №16

Турай авыл җирлеге территориясендә
төзекләндерү, яшелләндерү һәм
санитар тәртип урнаштыру буенча
язгы икеайлыкны оештыру һәм үткәрү турында

Тиешле санитар тәртипне тәэмин итү, торак пунктларның территорияләрен төзекләндерү буенча кичектергесез эшләр башкару һәм Турай авыл җирлегендә имин санитар-эпидемиологик хәл булдыру максатларында, Турай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 01.04.2020 елдан 31.05.2020 елга кадәр Турай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, яшелләндерү, санитария торышын яхшырту буенча язгы икеайлык үткәрергә.
2. Расларга:

   2.1. Турай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар тәртип урнаштыру буенча язгы икеайлыкны оештыру һәм үткәрү комиссиясе составын расларга (1 нче кушымта).

   2.2. Турай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар тәртип урнаштыру буенча язгы икеайлыкны оештыру һәм үткәрү буенча 2020 елга чаралар планын расларга (2 нче кушымта)

3. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Турай авыл җирлеге Башлыгы А.М.Рәхимова

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгының
2020 елның 1 апреленнән
16 нчы номерлы карарына

Турай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар тәртип урнаштыру буенча язгы икеайлыкны оештыру һәм үткәрү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Рәхимова А.М. | Турай авыл җирлеге Башлыгы |
| Вәлиева Л.Н. | Турай авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Димөхәммәтов Р.М | Турай урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Салихова Л.М. | Турай авылы "Карлыгач" балалар бакчасы мөдире (килешү буенча) |
| Гарипов А.С. | Татар Әхтиялы авылы ФП мөдире (килешү буенча) |
| Бәйрәмгалиева З.М. | Турай авылы китапханә мөдире (килешү буенча) |
| Мөхәмәтхатипова Ф. Ш. | Турай авылы мәдәният йорты директоры (килешү буенча) |
| Минерахманова А.Р. | Татар Әхтиялы авыл клубы директоры (килешү буенча) |
| Нигъмәтҗанов А.Н. | «Нигматзянов» КФХ җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гришанин Е. В. | Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районындагы участок полиция хезмәткәре (килешү буенча) |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы

Турай авыл җирлеге башлыгының
2020 елның 1 апреленнән
16 нчы номерлы карарына

Турай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар тәртип урнаштыру буенча язгы икеайлыкны оештыру һәм үткәрү буенча 2020 елга чаралар планы

| № | Чаралар исеме | Үтәү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| I. Оештыру чаралары | | | |
| 1. | Турай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар тәртип урнаштыру буенча икеайлыкны оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча барлык милек формасындагы учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрү. | 01.04.2020 ел | Комиссия рәисе |
| 2. | Авыл җирлеге территорияләрен участок чикләрен төгәл билгеләүче учреждениеләргә беркетү һәм санитария торышы, төзекләндерү һәм яшелләндерү өчен җаваплы затларны билгеләү | 01.04.2020 ел | Комиссия рәисе, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 3. | Эшкә яраклы пенсионерларның һәм эшләмәүче гражданнарның икеайлыгында ирекле рәвештә катнашуын оештыру | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| 4. | Икеайлыкта катнашучыларны кирәкле хуҗалык инвентаре белән тәэмин итү | Икеайлык дәвамында | Комиссия рәисе |
| 5. | Икеайлык чорында чүп чыгару өчен техниканы бүлеп биру һәм аларны бюджет оешмаларына бүлү | Икеайлык дәвамында | Комиссия рәисе |
| 6. | Санкцияләнмәгән чүплекләр барлыкка килүне һәм чүп-чар яндыруны кисәтү максатларында патрульлек итүне оештыру | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| 7. | Авылларда яшәүчеләрнең ишегалды территорияләрен чистартуда катнашуын тәэмин итү( халыкка мөрәҗәгатьләрне тарату, торак активы, ветераннар белән эш алып бару һ.б. | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| II. Төзекләндерү буенча чаралар | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Авыл советы территориясендә урнашкан һәйкәлләрне тиешле хәлгә китерү | Апрель-май | Комиссия әгъзалары |
| 9. | Язгы агач һәм куаклар утырту. Чәчәкләрне яңартуга керешергә. | Май | Авыл җирлеге территориясендә урнашкан барлык оешмалар (килешү буенча) |
| 11. | Җәмәгать транспорты тукталышларының булуына һәм аларның торышына ревизия үткәрү | Икеайлык дәвамында | Комиссия рәисе |
| 12. | Янгын гидрантларын төзекләндерү | Икеайлык дәвамында | Комиссия рәисе |
| 13. | Авыл җирлегендә зиратларны чистарту | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| 14. | Һәйкәлләр территорияләрен санитар чистартуны оештыру | Апрель-май | Комиссия әгъзалары |
| 15. | Санкцияләнмәгән чүплекләрне ачыклау һәм аларны юкка чыгару | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| 16. | Күзәтүчесез хайваннарның санын киметү буенча чаралар | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| 17 | Үз территорияләре чикләрендә шәхси йорт хуҗалыклары ишегаллары территорияләрен чүп-чардан арындыру | Май | Йорт хуҗалыклары хуҗалары |
| III. Яшелләндерү буенча чаралар | | | |
| 21. | Авария хәлендәге һәм корыган агачлардан арыну, корыган агачларның тамырларын һәм кәүсәләрен алып ату. Урамнарда агачларны санитар кисү | Икеайлык дәвамында | Комиссия рәисе, Комиссия әгъзалары |
| 22. | Урман утырту көне | апрель | Комиссия рәисе |
| 23. | Мәдәният йорты, мәйдан, хоккей корты территориясендә агач һәм куаклар утырту. | Апрель-май | Комиссия әгъзалары |
| 24. | Учреждение территориясендә клумбалар әзерләү һәм чәчәкләр утырту | Май | Комиссия әгъзалары |
| IV. Икеайлык үткәрүне контрольдә тоту, учреждениеләрнең эш-гамәлләрен координацияләү, халыкка мәгълүмат бирү буенча чаралар | | | |
| 25. | Министрлык карамагындагы территорияләрдә санитар чистарту эшләрен оештыру белән бердәм санитар көн – шимбә өмәләре үткәрү | атна саен | Комиссия әгъзалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 26. | Икеайлыкка әзерлекне һәм аны үткәрүне координацияләү һәм контрольдә тоту | Икеайлык дәвамында | Комиссия әгъзалары |
| 27. | Йомгак ясау | Май | Комиссия рәисе |